**Класс:** 5
**Укытучы:** Шакирова Рузиля Раисовна
**Программа:** Вигасин А.А. Гомуми тарих. Борынгы заман тарихы. 5 сыйныф: татар телендә гомуми белем бирү оешмалары өчен уку әсбабы / - Казан: Татар.кит. нәшр., 2020.
**Тема:** Нил буендагы дәүләт.
**Максаты**: Мисыр иле, Нил ташулары белән таныштыру.
**Планлаштырылган нәтиҗә:** карта белән эшли белү, яңа терминнарны үзләштерү.

**(1 слайд)**

**I. Лекция. (2 слайд)**

**План:**

- **Мисыр иле;**
- **Нил ташулары;**
- **Мисырны берләштерү.**

Моннан 5 мең еллар элек беренче дәүләтләр барлыкка килә. Дәүләтләр игенчелек төп шөгыльгә әверелгән җирләрдә оеша. Игенчелек уңдырышлы туфраклы зур елгалар тирәсендә аеруча тиз үсә.

**(3 слайд)** Иң беренче патшалыкларның берсе Нил елгасы буенда барлыкка килгән.

Төньяк- Көнчыгыш Африкада чиксез зур чүлләр җәелгән. Шушы җирләр буйлап дөньяның иң зур елгаларыннан берсе – **Нил ага**. Аның озынлыгы **1200 км**. тәшкил итә. **(4 слайд)** Нил елгасын лотос чәчәгенә тиңлиләр: үзән җирдә - сабагы, Урта диңгезгә койганда елга зур тармакларга бүленә һәм ***дельта*** ясый- бу чәчәк өлешен хәтерләтә. Нил агымы үз юлында куркынычлы таш киртәләргә- бусагаларга очрый. Нилдан еракта комнар арасында сирәк кенә яшеллек утраулары – ***оазис*****лар** бар. Андый урыннарда җир астыннан бәреп чыккан чишмәләр тирәсендә пальмалар һәм куаклар үсә. Иң зур оазис Фаюм булган.

**(5 слайд)** Нил елгасының беренче бусагасыннан алып Урта диңгезгә кадәрге аралыкта урнашкан ил **Мисыр (Египет)** дип атала. “**Мисыр- Нилның бүләге**” , дигәннәр борынгылар.

**(6 слайд)** Җәй башында анда каты яңгырлар ява, тау түбәләрендәге карлар эри. Су ташкыннары, туфракны ашый-ашый, елгага ыргыла. Кызгылт тау токымнарының вак кисәкчекләре белән тулы болганчык су Нилга агып төшә. Нилның суы башта болганчык яшел, соңыннан кызыл төскә керә. Су бөтен үзәнлекне тутыра, сусаган җирләрне терелткән Нил үзе белән үзенлеккә ләм алып килә. Һәр елның июлендә Нилда ташу башлана. **(7 слайд)** Июльдән ноябрьгә кадәр Нилның ташу чоры – ***ахет***; ноябрьдән мартка кадәр- үсү (яшелләнү) чоры- ***перет*****;** марттан- июльгә корылык чоры- ***хемо*** дип йөртелә. Бары тик ноябрьдә генә Нилның сулары үз юлына кайткан һәм ул яңадан үтә күренмәле зәңгәр төс алган. Нил ярларында урманнар булмаган, **(8 слайд)** ләкин 2-3 кеше биеклегендәге папируслар үскән. Папирусны мисырлылар бик актив кулланганнар:

- Кәүсәсеннән балчык белән сылап алачык һәм көймәләр ясаганнар;
- Юка чыбыклардан сандаллар, ятып йоклау өчен циновкалар ясаганнар;
- Яшь чыбыкларны ризык итеп тә кулланганнар;
- Юка сабаклардан язу әсбаплары ясаганнар.

Мисырда яңгырлар булмый диярлек. Барча тереклек сусаудан хәлсезләнгән вакытта су арта башлый. **(9 слайд)** Мисырлылар, түбәнлекләрне артык судан саклау өчен, балчыктан өеп, дамбалар ясаганнар. Кырларда суны саклау өчен, игенчеләр плотиналар ясаганнар, каналлар казыганнар. Бу авыр хезмәт күп көч таләп иткән, шуңа игенчеләр общиналарга берләшкәннәр, ә общиналар ***ном*****нарга**. Бу кечкенә патшалыклар (номнар) саны кырыкка якын булган. Алар үзара сугышып торганнар – һәркем күршесен яулап алырга омтылган. **(10 слайд)** Нәтиҗәдә ике зур патшалык барлыкка килгән: Нилның түбән агымында – дельтада **- Төньяк Мисыр** урнашкан, ә үрге агымында – **Көньяк Мисыр**. **(11 слайд)** Көньяк Мисыр патшасы озын шлемга охшаган ак таҗ кигән. Төньяк Мисыр патшасының таҗы кызыл төстә булган, арты бераз калкып торган.

Ике патшалык арасында рәхимсез сугышлар барган. Бу чор турында мәшһүр (12 слайд) **Мисыр рельефы** – ташка кисеп ясалган кабарынкы рәсем сөйли. Анда Көньяк Мисыр таҗын кигән патша үзенең дошманына кизәнгән итеп сурәтләнгән. Аста качып баручы дошманнар күрсәтелгән. Б.э.к. 3 мең еллар элек Көньяк Мисыр патшасы Төньяк Мисырны тулысынча буйсындырган һәм илне берләштергән. Патшаның исеме төгәл билгеле түгел, греклар аны Мина (Менее), мисырлылыр Нармер дип атаганнары гына мәгълүм. Ул берсе икенчесе эченә беркетелгән сыман ике катлы таҗ кия башлаган. Мисырның хөкемдарларын фиргавеннәр дип йөртәләр. Мисыр дәүләтенең беренче башкаласы Мемфис шәһәре булаган.

## II. Практика.

**Беренче бирем.**

**(1 слайд)**Таблицадагы буш урыннарны тутырыгыз

| Аңлатма | Термин |
|---|---|
| | Мисырлыларның хуҗалыгында актив кулланыла торган тростник пальмасы |
| | Елгадагы ташлы бусагалар |
| | Төньяк Мисырда елганың киңәеп киткән зур өчпочмакка ошаган өлкәсе |
| | Чүлдәге яшел утраучык |

**(2 слайд)**Җаваплар:

| Аңлатма | Термин |
|---|---|
| **Папирус** | Мисырлыларның хуҗалыгында актив кулланыла торган тростник пальмасы |
| **Порог** | Елгадагы ташлы бусагалар |
| **Дельта** | Төньяк Мисырда елганың киңәеп киткән зур өчпочмакка ошаган өлкәсе |
| **Оазис** | Чүлдәге яшел утраучык |

**(3 слайд)Икенче бирем.**

**Текста буш урыннарны туры килә торган сүзләр белән тутырыгыз.**

Нил агымы үз юлында куркынычлы таш киртәләргә ______ очраган. _____диңгезгә койганда елга зур өчпочмак ясый торган берничә тармакка бүленгән. Бу аның _______ сы. Нилдан еракта комнар арасында сирәк кенә яшеллек утраулары___________ лар очраган. Андый урыннарда җир астыннан бәреп чыккан чишмәләр тирәсендә пальмалар һәм куаклар үскән.

Сүзләр: *дельта, оазис, бусага, Урта*

**(4 слайд) Җаваплар:**

Нил агымы үз юлында куркынычлы таш киртәләргә ***бусагаларга*** очраган. ***Урта*** диңгезгә койганда елга зур өчпочмак ясый торган берничә тармакка бүленгән. Бу аның ***дельта***сы. Нилдан еракта комнар арасында сирәк кенә яшеллек утраулары ***оазис***лар очраган. Андый урыннарда җир астыннан бәреп чыккан чишмәләр тирәсендә пальмалар һәм куаклар үскән.

**Өченче бирем.**

**(5 слайд) Хаталарны табыгыз.**

Б.э.к. 5 мең еллар элек Төньяк Мисыр патшасы Көньяк Мисырны өлешчә буйсындырган һәм илне берләштергән. Ул берсе икенчесе эченә беркетелгән сыман ике катлы таҗ киеп йөри башлаган. Мисырның хөкемдарын кенәз дип йөртәләр. Мисыр дәүләтенең беренче башкаласы Хеопс булган.

**(6 слайд) Җавап:**

Б.э.к**. (**5) **3** мең еллар элек Мисыр (Төньяк) **Көньяк** патшасы (Көньяк**)** **Төньяк** Мисырны (өлешчә) **тулысынча** буйсындырган һәм илне берләштергән. Ул берсе икенчесе эченә беркетелгән сыман ике катлы таҗ киеп йөри башлаган. Мисырның хөкемдарын (кенәз) **фиргавен** дип йөртәләр. Мисыр дәүләтенең беренче башкаласы (Хеопс) **Мемфис** булган.